ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

______17.01.2025_____ **Чистай шәһәре** **№ _7_**

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү хакында» 2024 елның 23 сентябрендәге 417 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 октябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 өлешендәге «а» пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 өлешенең икенче абзацы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты**

**КАРАР БИРӘ:**

**1.«Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 23 сентябрендәге 417 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:**
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «ТР Административ хокук бозулар кодексында каралган административ хокук бозулар составлары исемлеге» 23.09.2025 ел, № 417 карарына кушымтаның «ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.16 статьясы - транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) урнаштырган өчен түләмәү» юлын яңа редакциядә бәян итәргә:
**«Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 3.16 статьясы - муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу».**
2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга .

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы Башкарма
комитетының карарына
кушымта
23.09.2024 ел, № 417
( 17.01.2025 ел №___7___карары ред.)

**ТР АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР КОДЕКСЫНДА КАРАЛГАН АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР СОСТАВЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ**

| ТР КоАП статьялары | Административ хокук бозу составы |
|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.1 статьясы | Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын, башка дәүләт органын, җирле үзидарә органын, предприятиене, учреждениене, башка оешманы үз исеме һәм мәгълүматны чыгарырга тиешле башка белешмәләр күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата) |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.4 статьясы | Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.5 статьясы | Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә тагып йөрү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.6 статьясы | Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.7 статьясы | Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу |
| 2 өлеш ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.15 статьясы | Террорчылыкны профилактикалау, аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.17 статьясы | Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.19 статьясы | Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.20 статьясы | Сыекландырылган углеводород газы булган гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен балигъ булмаган товарларны ваклап сатуны чикләүне, шулай ук, сыекландырылган углеводород газын сулау юлы белән, балигъ булмаганнарны куллануга җәлеп итүне үтәмәү |

| | |
|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.21 статьясы | Режим кысаларындагы (база әзерлеге дәрәҗәсендәге) чараларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.2 статьясы | Урамда сәүдә оештыру һәм халыкның күңел ачуларына бәйле хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозу. |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.3 статьясы | Җир асты коммуникацияләрен тоту кагыйдәләрен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.4 статьясы | Урамнарны, квартал эчендәге яктыртуны тоту кагыйдәләрен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.5 статьясы | Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.6 статьясы | Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.8 статьясы | Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.10 статьясы | Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен (гражданнарга карата) бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.11 статьясы | Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләр булмау |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.14 статьясы | Мәдәни-тамаша чараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.15 статьясы | Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.15 статьясы | Иҗтимагый урыннарда товарлар һәм хезмәтләр күрсәтү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.16 статьясы | Муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу |

| | |
|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.17 статьясы | яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чараларын урнаштыру |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 4.4 статьясы | Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 5.1 статьясы | Билетсыз йөрү |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 5.2 статьясы | Багаж алып бару кагыйдәләрен бозу |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 5.6 статьясы | Пассажирны йөртүдә баш тарту |